КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 11 март г.Казань № 229

**2023 елда төбәк операторы тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 31 декабрь, 1146 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча төбәк программасын финанслауга сарыф ителергә хокуклы акча күләмен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 185 статьясындагы 2 өлеше һәм «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 1 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

2023 елда төбәк операторы тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча төбәк программасын раслау турында» 2013 ел, 31 декабрь, 1146 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча төбәк программасын финанслауга сарыф ителергә хокуклы акча күләмен (киләсе чорда уртак мөлкәтенә капиталь ремонт ясалырга тиешле күпфатирлы йортлардагы бүлмәләрнең милекчеләре тарафыннан формалаштырылган капиталь ремонт фондлары акчасы исәбеннән бирелә торган акча күләмен) 4 959,96 млн.сум күләмендә билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин